| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Енабердинского сельского<br>поселения Менделеевского<br>муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Менделеевск муниципаль районы<br>Енабердино авыл җирлеге Советы |
| --- | --- |

| Р Е Ш Е Н И Е<br>2021 елның 22 мартыннан | К А Р А Р<br>№ 21 |
| --- | --- |

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 84 номерлы Енабердино авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча 2021 елның 22 апрелендә 17 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы, Енабердино авыл җирлеге, Енабердино авылы Клуб ур., 7 йорт, мәдәният йорты бинасының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының

«Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Советы карары проекты белән таныштырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Енабердино авыл җирлеге, Енабердино авылы, Клуб ур., 7 йорт, мәдәният йорты бинасының актлар залы.;

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Енабердино авыл җирлеге Советы рәисе                    Е.Н.Никифоров

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге
Советының
2021 елның 22 мартындагы
21 нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Никифоров Евгений Николаевич - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгы;
2. Рәис урынбасары: Антонова Майя Агафоновна - Енабердино авыл мәдәният йорты директоры;
3. Секретарь: Аксакова Нина Николаевна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Васильев Леонид Николаевич – Енабердино авыл җирлеге Советы депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Махмудов Эльдар Абталыб оглы – Енабердино авыл җирлеге Советы депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.